| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.05 2019 № 336

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 9 октябрендәге
«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
территориясендә шәһәр яны элемтәсенең
муниципаль маршрутлары буенча
җайга салынган тарифлар буенча автомобиль транспортында
даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә
бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатында,
транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»
570 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе 5 пункты, РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр житештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында " 887 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1.ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 9 октябрендәге «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча җайга салынган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатында, транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 570 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.3.1 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- субсидия алучылар башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге документның 1.2 пунктында күрсәтелгән

максатларга «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан акча алырга тиеш түгел;

1.2.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.2. Бюджет акчаларын алучы буларак баш идарәче һәм субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү тиешле субсидия төре өчен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы финанс органы тарафыннан билгеләнгән типтагы форма нигезендә төзелә.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча җайга салынган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатында, транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенең 2нче Кушымтасын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының http://www. spassriy.tatarstan.ru рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н. А Казаковага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин